**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ГОСУДАРСТВЕННОЕ АВТОНОМНОЕ ПРОФЕССИОНАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ**

**«АКТАНЫШСКИЙ ТЕХНОЛОГИЧЕСКИЙ ТЕХНИКУМ»**

# ОГСЭ.05. «Татарский язык в профессиональной деятельности”

**ПРОГРАММА УЧЕБНОЙ ДИСЦИПЛИНЫ**

Для среднего профессионального образования **по специальности 36.02.01. Ветеринария**

Актаныш, 2021

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ**
**ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ ҺӨНӘРИ МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
**"АКТАНЫШ ТЕХНОЛОГИЯ ТЕХНИКУМЫ"**

# ОГСЭ.05. **"Һөнәри эшчәнлектә татар теле"**

**УКУ ДИСЦИПЛИНАСЫ ПРОГРАММАСЫ**

**Ветеринар белгечлеге 36.02.01.** буенча урта һөнәри белем бирү өчен

Актаныш, 2021

# Уку дисциплинасы программасы

"Ветеринар белгечлеге 36.02.01 буенча урта һөнәри белем бирү өчен федераль дәүләт белем бирү стандартын раслау турында", 2016 ел 9 декабрь 1564 номерда чыгарылган РФ фән һәм мәгариф министрлыгы боерыгы,

урта һөнәри белем бирү өчен федераль дәүләт белем бирү стандарты нигезендә төзелде

Программа төзүче мәгариф учреждениесе: *Актаныш технология техникумы*

Төзүче: *Әхмәтҗанова Хәмдия Әхтәм кызы, Актаныш технология техникумының татар теле һәм әдәбияты укытучысы*

ДАҺМУ "Актаныш технология техникумы"ның методик комиссия утырышында каралды

беркетмә №1, 30 август 2021 ел.

| Килешенде | Раслыйм |
|---|---|
| ДАҺМУ "Актаныш технология техникумы" ның уку - укыту эшләре буенча директор урынбасары<br>__________ / Нуруллин Р. З./<br>« 31 » август 2021 ел | ДАҺМУ "Актаныш технология техникумы" директоры<br>__________ /Шәмсунова Л. Я./<br>Приказ №____ « 31 » август 2021 ел |

# Эчтәлек

бит


1. **Уку дисциплинасы программасының паспорты** 4 - 9

2. **Уку дисциплинасының төзелеше һәм эчтәлеге** 10 - 15

3. **Уку дисциплинасын тормышка ашыру шартлары** 16 - 19

4. **Уку дисциплинасын үзләштерү нәтиҗәләренә контроль** 20 - 27 **һәм билге**

## 1. Уку дисциплинасы паспорты Һөнәри эшчәнлектә татар теле

Бу программа һөнәри эшчәнлектә татар теле фәненнән Актаныш Технология техникумында белем алучы татар телле укучылар өчен төзелде һәм түбәндәге документка нигезләнеп эшләнде:

- Башлангыч һөнәри белем бирү училищелары һәм лицейлары өчен татар теленнән программа.

Татар теленнән программа белем эчтәлеген заман таләпләренә туры китереп яңарту, аның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү бурычларын хәл итү максатында Актаныш Технология техникумы өчен төзелде. Ул һәр укучының татар теле һәм әдәбиятыннан түләүсез яхшы сыйфатлы белем алуга хокукын гарантияли, һәр укучыга тигез мөмкинлекләр тудыра.

Программа нигезендә татар теленнән белем күләме билгеләнә, укыту - методик комплектлар эшләнә.

Тугыз сыйныф белеме белән килгән укучы, татар теле буенча төпле һәм системалы белемгә ия булырга тиеш.

Яшь буынны физик яктан һәм акыл хезмәтенә, җәмгыять һәм дәүләт тормышының барлык өлкәләрендә, фән һәм мәдәнияттә актив эшчәнлеккә сәләтле итеп тәрбияләү бурычын хәл итүдә, техникумда татар баласына ана теле һәм әдәбиятын тирәнтен бирү, аларны татар халкының тарихы һәм мәдәнияте белән таныштыру хәзерге шартларда тагын да актуальләшә.

Гомуми белем бирүнең максаты - укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен камильләштерү, сөйләм культурасын үстерүдән гыйбарәт. Тәрбияви максат студентларның рухи дөньяларын баету, аларны татар халкының мәдәнияте һәм сәнгате белән таныштыру, төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләүгә юнәлтелә. Шушы максатлардан чыгып, программада укучылар өчен бурычлар куела:

- мәктәптә алган белемнәрне тирәнәйтү;
- укучыларны татар әдәби телендә иркен сөйләшергә өйрәтү, аларга ана телендәге әдәбиятны мөстәкыйль укып аңлау һәм үз фикерләрен сөйләмә яки язма рәвештә формалаштыра белү күнекмәләре бирү;
- татар әдәбияты һәм халык авыз иҗатының бай тарихына күзәтү ясау;

- татар телен һәм әдәбиятын укыту дәверендә һәм дәресләрдән тыш үткәрелгән чараларда студентларның рухи дөньяларын баету, патриотик, әхлакый һәм эстетик тәрбия бирү, милли үзаң һәм милли горурлык хисләре тәрбияләү.

Тәкъдим ителгән программа " Башлангыч һөнәри белем бирү училищелары һәм лицейлары өчен татар теле һәм әдәбиятыннан программа" га һәм дәреслекләргә нигезләнеп төзелде:

- Зәкиев М. З., Максимов Н. В. Татар теле. 10 -11 сыйныфлар өчен дәреслек. - Казан: Мәгариф, 2008;

- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек. Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;

- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 11 нче сыйныф өчен дәреслек. Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017.

Һөнәри эшчәнлектә татар теле программасы (I курслар өчен) 96 сәгатькә исәпләнгән, нигездә, аларның аласы һөнәрләренә бәйләп, фонетика, лексика, морфология, синтаксис бүлекләрен өйрәнү каралып, изложение һәм сочинение күнекмәләре бирелә. Шулай ук телнең килеп чыгышы, тел галимнәре, диалектлар, татар телендә язу графикалары, телләр турындагы законнарны өйрәнү карала. Бүлек ахырында шулай ук изложение һәм сочинение язуга таләпләр күрсәтелә.

## 1.1. Программаны куллану тирәлеге

Уку дисциплинасы программасы урта башлангыч һөнәри белем бирү өчен федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә эшләнгән төп белем бирү программасының бер өлеше булып тора. Бу программа **Ветеринар белгечлеге хәзерли торган группа студентлары** өчен төзелде (001 в)

Уку дисциплинасы программасы эшче һөнәрләре буенча өстәмә һөнәри белем бирү һәм һөнәри әзерлекләр өчен дә кулланыла ала.

1.2. **Төп һөнәри белем бирү программасы структурасында уку дисциплинасы урыны:** дисциплина гомумбелем бирү циклына керә.

1.3. **Уку дисциплинасының максаты һәм бурычлары – дисциплинаны үзләштерү нәтиҗәләренә таләпләр.**

***Татар теле фәнен үзләштергәннән соң студент белергә тиеш:*** Фонетик һәм орфоэпик принципларны, орфографик һәм грамматик кагыйдәләрне дөрес итеп урынлы куллана белергә; җөмләгә билгеләмә бирергә, әйтелешләре ягыннан җөмлә төрләрен, җөмләнең баш кисәкләрен, җөмләнең иярчен кисәкләрен, җыйнак һәм җәенке җөмләләрне аера белергә. Ияртүле һәм тезүле бәйләнешне аера белергә . Татар теленең сүз байлыгын барлап, аңа характеристика бирергә. Сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең лексик мәгънәләрен аңлатырга, аларга синоним омоним, антонимнар табарга. Бер һәм күп мәгънәле сүзләрне аера белергә. Аңлатмалы, энциклопедик, этимологик, тәрҗемәле сүзлекләр белән эшләргә.

***Эшләргә тиеш***: Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен аерырга. Җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес куярга. Чиста һәм орфография кагыйдәләрен дөрес кулланып язарга, үз фикерләрен сөйләм һәм язма формаларда логик яктан эзлекле, төгәл һәм җыйнак итеп биреп эшләргә тиеш.

Татар теленең сүз байлыгын барларга, аңа характеристика бирергә. Сүзләрнең һәм фразеологик әйтелмәләрнең лексик мәгънәләрен аңлатырга, аларга синоним, омоним, антонимнар табарга. Бер һәм күп мәгънәле сүзләрне аера белергә. Аңлатмалы, энциклопедик, этимологик, тәрҗемәле сүзлекләр белән эшләргә.

**4. Уку дисциплинасы программасын үзләштерү өчен тәкъдим ителгән сәгатьләр саны:** укучыга максималь уку йөкләнеше 123 сәгать, шуңардан мәҗбүри уку дәресе 96 сәгать мөстәкыйль дәресләр 27 сәгать

# Уку дисциплинасының төзелеше һәм якынча эчтәлеге

## 2.1. Уку дисциплинасының зурлыгы һәм уку эшләренең төрләре

| **Уку эшләренең төрләре** | **Сәгатьләр саны** |
|---|---|
| **Максималь уку йөкләнеше (барлыгы)** | **123** |
| **Мәҗбүри уку йөкләнеше (барлыгы)** | **96** |
| шуңардан: | |
| практик дәресләр | - |
| контроль – язма эшләр | 10 |
| **Укучының мөстәкыйль эшләре (барлыгы)** | 27 |
| шуңардан: | |
| мөстәкыйль эшләрнең тематикасы | 12 |
| сөйләм телен үстерү | 7 |
| тестлар | 5 |

| | |
|---|---|
| рефератлар | 3 |
| **Йомгаклау аттестациясе  -** дифзачёт | |

# 2.2. “Һөнәри эшчәнлектә татар теле” уку дисциплинасының эчтәлеге һәм календарь – тематик план

| Бүлек һәм темаларның исемнәре | № | | Уку материалы, лаборатор һәм практик дәресләр, укучыларның мөстәкыйль эшләренең эчтәлеге | Сәгатьләр күләме | Сәгатьләр саны | Үзләштерү дәрәҗәсе | Үткәрү вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | максималь | мәҗбүри | **Уку материалының эчтәлеге** | | | | |
| **Тема 1. Тел – аралашу чарасы, иҗтимагый һәм сәяси күренеш.** | 1 | 1 | Тел турында гомуми мәгълүмат. Дәүләт теле буларак татар теленең роле | 9 | 1 | 2 | |
| | 2 | 2 | Телнең төп функцияләре | | 1 | 2 | |
| | 3 | 3 | Төрки телләр | | 1 | 2 | |
| | 4 | 4 | Татарлар яши торган төбәкләр | | 1 | 2 | |
| | 5 | 5 | Башка телләр арасында татар теленең урыны | | 1 | 2 | |
| | 6 | 6 | Татар теле белеменең төп тармаклары | | 1 | 2 | |
| | 7 | 7 | Тел һәм сөйләм | | 1 | 2 | |
| | 8 | 8 | Тел – үсеп-үзгәреп торучы иҗтимагый күренеш | | 1 | 2 | |
| | 9 | 9 | Тел – шартлы билгеләр системасы | | 1 | 2 | |
| **Тема 2. Сөйләм үзенчәлекләре** | 10 | 10 | Сөйләм үзенчәлекләре | 4 | 1 | 2 | |
| | 11 | 11 | Татар теле һәм сөйләм культурасы Сөйләм төгәл булсын | | 1 | 2 | |
| | 12 | 12 | Сөйләм аңлаешлы булсын Сөйләм саф булсын | | 1 | 2 | |
| | 13 | 13 | Сөйләм җыйнак булсын Сөйләм аһәңле булсын | | 1 | 2 | |
| | 14 | 14 | Контроль диктант | 1 | 1 | 2 | |
| | 15 | 15 | Тартык һәм сузык авазлар | | 1 | 2 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Тема 2. Фонетика** | 16 | 16 | Сингармонизм, ассимиляция, редукция күренешләре | 4 | 1 | 2 | |
| | 17 | 17 | Орфоэпия, графика, орфография | | 1 | 2 | |
| | 18 | 18 | Иҗек, басым, интонация | | 1 | 2 | |
| **Тема 3. Лексика** | 19 | 19 | Татар теленең сүзлек составы | 3 | 1 | 2 | |
| | 20 | 20 | Фразеологизм һәм омонимнар | | 1 | 2 | |
| | 21 | 21 | Синоним, антоним һәм алынма сүзләр | | 1 | 2 | |
| | 22 | 22 | Искәртмәле диктант | 1 | 1 | 2 | |
| | | | **Лаборатор дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Практик дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Укучыларның мөстәкыйль дәресләре** | | | | |
| | 23 М1 | | Тел турында | 3 | 1 | 3 | |
| | 24 М2 | | Сингармонизм, ассимиляция, редукция күренешләре | | 1 | 3 | |
| | 25 М3 | | Лексика. Кроссворд | | 1 | 3 | |
| **Тема 4. Морфология** | 26 | 23 | Исем. Исемнәрнең сан, килеш, тартым белән төрләнеше | 9 | 1 | 2 | |
| | 27 | 24 | Фигыль. Фигыль юнәлешләре | | 1 | 2 | |
| | 28 | 25 | Фигыль төркемчәләре | | 1 | 2 | |
| | 29 | 26 | Татар телендә сүз төзелеше һәм ясалышы | | 1 | 2 | |
| | 30 | 27 | Сыйфат турында төшенчә. Ныгыту күнегүләре | | 1 | 2 | |
| | 31 | 28 | Сан турында төшенчә. Сан төркемчәләре | | 1 | 2 | |
| | 32 | 29 | Рәвеш турында төшенчә. Сөйләмдә аларның кулланылышы | | 1 | 2 | |
| | 33 | 30 | Алмашлык. Зат алмашлыклары | | 1 | 2 | |
| | 34 | 31 | Күрсәтү алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше | | 1 | 2 | |
| | 35 | 32 | Контроль изложение “Әбиемнең куллары” | 4 | 1 | 3 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 36 | 33 | Контроль изложение “Әбиемнең куллары” | | 1 | 3 | |
| | 37 | 34 | Ирекле темага сочинение | | 1 | 3 | |
| | 38 | 35 | Ирекле темага сочинение | | 1 | 3 | |
| | | | **Лаборатор дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Практик дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Укучыларның мөстәкыйль дәресләре** | | | | |
| | 39 М4 | | Морфология. Исем - тест | 5 | 1 | 3 | |
| | | | | | | | |
| | 40 М5 | | Фигыль - заманнар | | 1 | 3 | |
| | 41 М6 | | Сыйфат. Ныгыту күнегүләре | | 1 | 3 | |
| | 42 М7 | | Сан төркемчәләре | | 1 | 3 | |
| | 43 М8 | | Зат алмашлыклары - хикәя | | 1 | 3 | |
| | | | **Уку материалының эчтәлеге** | | | | |
| **Тема 5. Стилистика** | 44 | 36 | Икетеллелек шартларында тел культурасы | 7 | 1 | 2 | |
| | 45 | 37 | Әдәби тел. Әдәби язма һәм сөйләмә телгә төп таләпләр | | 1 | 2 | |
| | 46 | 38 | Стильләр турында гомуми мәгълүмат | | 1 | 2 | |
| | 47 | 39 | Эпистоляр һәм фәнни стильләр | | 1 | 2 | |
| | 48 | 40 | Рәсми стиль | | 1 | 2 | |
| | 49 | 41 | Әдәби һәм публицистик стильләр | | 1 | 2 | |
| | 50 | 42 | Туры һәм кыек сөйләм | | 1 | 2 | |
| | 51 | 43 | Контроль диктант | 1 | 1 | 3 | |
| | | | **Лаборатор дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Практик дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Укучыларның мөстәкыйль дәресләре** | | | | |
| | 52 М9 | | Икетеллелек, күптеллелек | | 1 | 3 | |
| | 53 М10 | | Сочинение – тасвирлама язу | 3 | 1 | 3 | |
| | 54 М11 | | Автобиография язу | | 1 | 3 | |
| | | | **Уку материалының эчтәлеге** | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Тема 6. Синтаксис** | 55 | 44 | . Сүзтезмәләрнең төрләре | 1 | 1 | 2 | |
| **Гади җөмлә** | 56 | 45 | Гади җөмлә | 5 | 1 | 2 | |
| | 57 | 46 | Ике составлы җөмләләр | | 1 | 2 | |
| | 58 | 47 | Тулы һәм ким җөмләләр | | 1 | 2 | |
| | 59 | 48 | Җөмләнең баш кисәкләре | | 1 | 2 | |
| | 60 | 49 | Җөмләнең иярчен кисәкләре | | 1 | 2 | |
| **Кушма җөмлә** | 61 | 50 | Кушма җөмлә синтаксисы. | 7 | 1 | 2 | |
| | 62 | 51 | Тезмә кушма җөмләләр | | 1 | 2 | |
| | 63 | 52 | Иярченле кушма җөмләләр | | 1 | 2 | |
| | 64 | 53 | Иярченле кушма җөмләләр. Күнегүләр эшләү | | 1 | 2 | |
| | 65 | 54 | Катлаулы кушма җөмләләр. Күп тезмәле кушма җөмлә | | 1 | 2 | |
| | 66 | 55 | Күп иярченле кушма җөмләләр | | 1 | 2 | |
| | 67 | 56 | Катнаш кушма җөмлә турында мәгълүмат | | 1 | 2 | |
| | 68 | 57 | Изложение “Кыш әбинең шуклыгы” | 2 | 1 | 2 | |
| | 69 | 58 | Изложение “Кыш әбинең шуклыгы” | | 1 | 2 | |
| | 70 | 59 | Контроль сочинение “Дустым булу – үзе зур бәхет” | 2 | 1 | 2 | |
| | 71 | 60 | Контроль сочинение “Дустым булу – үзе зур бәхет” | | 1 | 2 | |
| | | | **Лаборатор дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Практик дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Укучыларның мөстәкыйль дәресләре** | | | | |
| | 72 М12 | | Синтаксис. Сүзтезмәләрнең төрләре | 4 | 1 | 3 | |
| | 73 М13 | | Кушма җөмлә синтаксисы | | 1 | 3 | |
| | 74 М14 | | Тезмә кушма җөмләләр | | 1 | 3 | |
| | 75 М15 | | Катлаулы кушма җөмләләр - схемалар | | 1 | 3 | |
| | | | **Уку материалының эчтәлеге** | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **Тема 7. Телнең үсеше** | 76 | 61 | Телнең үсеше, яшәеше. | 4 | 1 | 2 | |
| | 77 | 62 | Җанлы һәм үле телләр турында | | 1 | 2 | |
| | 78 | 63 | Милли азчылыкларны ассимиляцияләү, саклау һәм үстерү сәясәте | | 1 | 2 | |
| | 79 | 64 | Татарстанда татар телен саклау һәм үстерү чаралары | | 1 | 2 | |
| **Тема 8. Татар милли әдәби теленең язма тамырлары** | 80 | 65 | Татар милли әдәби теле турындагы мәгълүматларны искә төшерү | 5 | 1 | 2 | |
| | 81 | 66 | Борынгы төрки әдәби тел. Рун язуы турында төшенчә | | 1 | 2 | |
| | 82 | 67 | Грамматик биремле диктант | | 1 | 2 | |
| | 83 | 68 | Иске төрки әдәби тел | | 1 | 2 | |
| | 84 | 69 | Иске татар әдәби теле | | 1 | 2 | |
| **Тема 9. Татарлар кулланган язу төрләре** | 85 | 70 | Гарәп графикасы | 9 | 1 | 2 | |
| | 86 | 71 | Гарәп графикасы. Күнегүләр эшләү | | 1 | 2 | |
| | 87 | 72 | Латин графикасына нигезләнгән язу | | 1 | 2 | |
| | 88 | 73 | Латинча шигырьләр уку һәм язу | | 1 | 2 | |
| | 89 | 74 | Татар язуында рус графикасы | | 1 | 2 | |
| | 90 | 75 | Татар язуында рус графикасы. Күнегүләр эшләү | | 1 | 2 | |
| | 91 | 76 | Эш кәгазьләре (белешмә, акт, васыятьнамә) | | 1 | 2 | |
| | 92 | 77 | Эш кәгазьләре (беркетмә, ышанычнамә) | | 1 | 2 | |
| | 93 | 78 | Үткәннәрне кабатлау өчен күнегүләр эшләү | | 1 | 2 | |
| | 94 | 79 | Контроль изложение “Кыр казы” | 2 | 1 | 2 | |
| | 95 | 80 | Контроль изложение “Кыр казы” | | 1 | 2 | |
| | | | **Лаборатор дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Практик дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Укучыларның мөстәкыйль дәресләре** | | | | |
| | 96 М16 | | Телнең үсеше, яшәеше | 7 | 1 | 3 | |
| | 97 М17 | | Иске татар әдәби теле | | 1 | 3 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 98 М18 | | Гарәп графикасы | | 1 | 3 | |
| | 99 М19 | | Татар милли әдәби теле | | 1 | 3 | |
| | 100 М20 | | Латин графикасы | | 1 | 3 | |
| | 101 М21 | | Татар язуында рус графикасы | | 1 | 3 | |
| | 102 М22 | | Эш кәгазьләре (белешмә, акт, васыятьнамә) | | 1 | 3 | |
| | | | **Уку материалының эчтәлеге** | | | | |
| **Тема 12. Тел тарихы** | 103 | 81 | Тел – милләтнең иң кыйммәтле тарихи ядкяре | 4 | 1 | 2 | |
| | 104 | 82 | Тел – милләтнең иң кыйммәтле тарихи ядкяре. Күнегүләр эшләү | | 1 | 2 | |
| | 105 | 83 | Ностратик берлектән төрки телләргә кадәр | | 1 | 2 | |
| | 106 | 84 | Телләрнең үзара тәэсир итешүләре | | 1 | 2 | |
| **Тема 13. Төрки – татар этнонимикасы** | 107 | 85 | Төрки – татар этнонимикасы. Төркиләрдә иң беренче этнонимнар | 7 | 1 | 2 | |
| | 108 | 86 | Аңлатмалы диктант | | 1 | 2 | |
| | 109 | 87 | Борынгы төрки этнонимнар теркәлгән регионнар | | 1 | 2 | |
| | 110 | 88 | Төрки этнонимнарның топоним буларак, Идел – Уралда теркәлеп калулары | | 1 | 2 | |
| | 111 | 89 | Татар этнонимының этимологиясе һәм семантикасы | | 1 | 2 | |
| | 112 | 90 | Татар теле галимнәре турында белешмә | | 1 | 2 | |
| | 113 | 91 | Татар теле галимнәре | | 1 | 2 | |
| | 114 | 92 | Контроль сочинение “Татарстаным – гөлстаным” | 2 | 1 | 2 | |
| | 115 | 93 | Контроль сочинение “Татарстаным – гөлстаным” | | 1 | 2 | |
| | | | **Лаборатор дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Практик дәресләр** | - | - | - | |
| | | | **Укучыларның мөстәкыйль дәресләре** | | | | |
| | 116 М23 | | Тел – милләтнең иң кыйммәтле тарихи ядяре | 5 | 1 | 3 | |
| | 117 М24 | | Ностратик берлектән төрки телләргә кадәр | | 1 | 3 | |
| | 118 М25 | | Төп диалектлар. Күнегүләр эшләү | | 1 | 3 | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 119 М26 | | Татар этнонимикасы. Күнегүләр эшләү | | 1 | 3 | |
| | 120 М27 | | Татар теле галимнәре | | 1 | 3 | |
| | 121 | 94 | Шәхси проектлар белән эш | 1 | 1 | 3 | |
| **Дифзачёт** | | 95 | | 2 | 1 | 2 | |
| | | 96 | | | 1 | 2 | |
| | | | Барысы | | 123 | | |

96 сәгать

# 3. Уку дисциплинасын тормышка ашыру шартлары

## 3.1. Минималь материаль – техник тәэмин итүгә таләпләр

Уку дисциплинасын тормышка ашыру татар теле һәм әдәбияты кабинетын яхшыртуны таләп итә

Уку кабинетын җиһазлау:

Китапханә фонды (китап бастыру продукциясе)

- Татар теле һәм әдәбиятыннан төп гомуми белем бирү стандарты
- Татар теле һәм әдәбиятыннан урта (тулы) гомуми белем бирү стандарты
- Татар теле һәм әдәбиятыннан төп гомуми белем бирү өчен үрнәк программа
- Татар теле дәреслеге - 10 – 11сыйныфлар өчен
- Татар теле - рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек
- Татар теле - рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 11 нче сыйныфы өчен дәреслек
- Әдәбият дәреслеге 10 сыйныфлар өчен - Әдәбият дәреслеге 11 сыйныфлар өчен
- Әдәбият - рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек
- Диктантлар җыентыгы – 10 – 11 сыйныфлар өчен
- Изложениеләр җыентыгы 10 – 11 сыйныфлар өчен
- Сочинениеләр җыентыгы 10 – 11 сыйныфлар өчен
- Татар теле һәм әдәбияты буенча бердәм дәүләт имтиханнары материаллары – җыентык
- Тестлар - җыентык

- Фәнни, фәнни – популяр, тарихи әдәбият

- Сүзлекләр, журналлар, альбомнар...
- Укытучы өчен методик китаплар

- Әдәби әсәрләр

## Басма ярдәмлекләр

- Татар теленнән таблицалар
- Әдәбияттан таблицалар
- Язучыларның портретлары

## Информацион – коммуникатив әсбаплар

- Әсәрләргә һәм язучыларга багышланган дисклар - Әсәрләргә һәм язучыларга багышланган видеофильмнар Уку өчен техник чаралар
- Компьютер
- Проектор
- Экран
- Уку - практик һәм уку – лаборатория җиһазлары
- Компьютер өстәле
- Җиһазларны саклау өчен бүлкәле шкаф
- Китап шкафы
- Укучылар санынча өстәлләр һәм урындыклар
- Укытучының эш урыны

**3.2. Укучыларны информацион тәэмин итү**

**Тәкъдим ителгән уку басмалары, интернет – ресурслар, өстәмә әдәбият** Төп китаплар:

- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек. Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;

- Р. К. Сәгъдиева. Татар теле. 11 нче сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;

- Ф. Ф. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина, Г. М. Әхмәтҗанова, Л. Ф.

Җамалиева. Татар әдәбияты. 10 нчы сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017;

- - Ф. Ф. Хәсәнова, Г. М. Сафиуллина, Г. М. Әхмәтҗанова, Л. Ф. Җамалиева. Татар әдәбияты. 11 нче сыйныф өчен дәреслек. - Казан. “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты. 2017.

**Өстәмә китаплар:**

Дәрес эшкәртмәсе үрнәкләре. Казан – 2012. Татар теле һәм әдәбияты. Р. А. Зарипов, А. М. Юсипова, Г. Ә. Гайнетдинова, Г. Г. Әхмәдуллина.

Татар әдәбиятыннан дәрестән тыш эшләр. Ә. Б. Шакирҗанова.

Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. Татар теле. Р. Р. Шәмсетдинова.

Олимпиадага әзерләү өчен ярдәмлек. Татар теле. Казан – 2014.

Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы. “Гыйлем” нәшрияты. – 2015.

**Интернет – ресурслар:**

http://tatar.com.ru/ все для изучения татарского языка http://kitap.net.ru/ татарская электронная библиотека

http:/www. Kitaphane.tatar.ru Национальная библиотека Республики Татарстан

http://tatar.info/ проект свободной многоязычной энциклопедии о татарской нации, её культуре, языке, истории и традициям znanium.com

## 4. Уку дисциплинасын үзләштерү нәтиҗәләренә контроль һәм билге

Уку дисциплинасын үзләштерү нәтиҗәләренә контроль һәм билге контроль һәм мөстәкыйль эшләр, тестлар үткәргән һәм шулай ук укучылар индивидуаль биремнәр, зачётлар эшләгән вакытта укытучы тарафыннан тормышка ашырыла.

**I – II КУРС УКУЧЫЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕННӘН**

# БЕЛЕМНӘРЕН БӘЯЛӘҮ

## 1. УКУНЫ БӘЯЛӘҮ

Укучыларның 1 минутта уку тизлеге түбәндәгечә билгеләнә:

| Группалар | Икенче ярты еллыкта | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | хәреф саны | | иҗек саны | | сүз саны | |
| I курслар | 465-735 | 495-765 | 190-290 | 200-300 | 85-130 | 90-135 |
| II курслар | 475-745 | 500-775 | 200-300 | 210-320 | 90-140 | 100-145 |

Уку барышында үтәлергә тиешле фонетик, орфоэпик, пунктуацион, грамматик таләпләрнең үтәлешенә нигезләнеп, бәяләр куелырга мөмкин: (алдагы таблицаны карагыз).

Искәрмәләр. 1) укуның төп максаты — текстның дөрес укылуына һәм эчтәлеген аңлауга ирешү;

2) укуны тикшереп бәя биргәнче, укучылар, укуны бәяләү нормалары белән таныштырылып, текст белән эшләү күнекмәләре алырга тиеш.

## ЯЗМА ЭШЛӘРНЕ БӘЯЛӘҮ

Тел буенча бирелгән белемнәрнең үзләштерелү дәрәҗәсен, язуда дөрес кулланылышын тикшерү максатыннан татар теле дәресләрендә төрле язма эшләр — диктант, изложение һәм сочинениеләр яздырыла. Диктантларны бәяләгәндә, орфографик һәм пунктуацион хаталарның саны, ә изложение белән сочинениеләрдә исә, орфографик һәм пунктуацион хаталар белән бергә, теманың ачылу дәрәҗәсе, язманың тел байлыгы (С), грамматик ялгышлары (Г.\, логик (Л.) һәм фактик (Ф.) хаталар да исәпкә алына.

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1.<br><br><br><br><br><br><br><br><br><br><br>2. | Шул сыйныфка таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиз, ачык, дөрес әйтелеп, фикер аңлаешлы бирелсә, ягъни:<br>— фонетик үзенчәлекләр (хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре) дөрес бирелсә;<br>— татар әдәби теленең орфоэпик нормалары (сүзнең язылыш һәм әйтелеш үзенчәлекләре) сакланса;<br>— җөмләләр сөйләмнең төп структур берәмлекләренә (сүзләр — иҗекләргә; җөмлә — сүз тезмәләре һәм сүзләргә, мәгънәле кисәкләргә) дөрес бүленсә;<br>— тукталышлар (паузалар) дөрес ясалса, сүз басымы һәм логик басым дөрес укылса яисә куелса;<br>— интонацион яктан тексттагы җөмләләр дөрес тавыш белән укылса; | «5»ле билгесе куела. |

| | | |
|---|---|---|
| | Укытучының текст эчтәлегеннән чыгып бирелгән сорауларына төгәл җавап бирелсә; | |
| 1.<br><br><br><br><br><br>2. | Таләп ителгән күләмдәге сүзләр (текст) тиешле тизлектә укылса, ләкин кайбер сүзләрнең әйтелешендә фонетик, орфэпик үзенчәлекләр тиешенчә үтәлмәсә ягъни:<br>— кайбер сүзләрне укыганда, сүзләрнең укылыш үзенчәлекләре орфоэпик нормаларга туры килмәсә;<br>— сөйләмнең структур бүленешендә кайбер хаталар булса;<br>— җөмләне укыганда, интонацион яктан 1-2 төгәлсезлек җибәрелсә;<br>Укытучының сорауларына төгәл җавап бирелсә; | «4» ле билгесе куела. |
| 1.<br>2.<br>3. | Уку тизлеге вакыт чикләренә сыймаса һәм уку барышында 3-4 фонетик, 2-3 орфоэпик хата җибәрелсә;<br>Текст сөйләм берәмлекләренә тиешенчә бүленмәү сәбәпле, интонация төгәл бирелмәсә;<br>Текстны аңлап та, сорауларга бирелгән җавапларда төгәлсезлекләр булса; | «3»ле билгесе куела. |
| 1.<br>2.<br>3.<br>4. | Тиешле тизлектә уку күнекмәләре булмаса;<br>Уку барышында үтелгән орфограммаларда төгәлсезлекләр күп кабатланса;<br>Уку барышында җибәрелгән фонетик, орфоэпик, интонацион хаталар текст эчтәлеген аңлауга комачауласа;<br>Текст эчтәлеге буенча бирелгән сорауларга өлешчә генә җавап алынганда; | «2» ле билгесе куела. |

Язма эшләрдә җибәрелгән хаталар тупас һәм тупас булмаган хаталарга бүленеп йөртелә.

Тупас хаталарга алдагы сыйныфларда һәм бу уку елында үтелгән орфографик, грамматик һәм пунктуацион кагыйдәләргә караган хаталар керә.

Тупас булмаган орфографик хаталар:

— укучы үзе төзәткән орфографик хаталар (өч хатасын үзе төзәткән укучының эше бер баллга түбән бәяләнә); язылышы татар теле кагыйдәләренә туры килмәгән ялгышлар (Акъегет, көньяк, төньяк, Сибгат һ. б.); мәгънәләре төрлечә кулланылган кушма яки тезмә сүзләрне бутап язу (аш казаны — ашказаны, бер үк — берүк, кай вакыт — кайвакыт, ике йөзле — икейөзле, ил гизәр — Илгизәр, өй алды — өйалды һ. б.);

— программа нигезендә өйрәнү күздә тотылмаган яки соңрак үteләчәк теоретик материалларга караган орфографик хаталар;

— беренче тапкыр очраган алынма сүзләрне, шулай ук тар профессиягә караган атамаларны язудагы хаталар;

— дәреслектә күрсәтелмәгән очракларга караган сүзне юлдан юлга күчерүдә ялгышу.

Тупас булмаган пунктуацион хаталарга җөмлә эчендәге синтагмаларны яки кушма җөмлә өлешләрен аеру өчен, функцияләре бердәй булган тыныш билгеләренең берсе урынына икенчесен кую (теркәгечләрдән башка бәйләнгән ике тиңдәш кисәкнең берсе икенчесенә каршы куюны белдергән очракта сызык яки өтер кую; гомумиләштерүче сүзләр янында — ике нокта яки сызык; аныклагычлар янына — сызык, ике нокта, җәяләр яки ике яктан өтер; ымлык яки аваз ияр-темнәреннән соң — өтер яки өндәү билгесе; теркәгечсез тезмә кушма җөмләдә — өтер, ноктaлы өтер яки сызык; тиңдәш кисәкләр арасында — өтер яки ноктaлы өтер; иярченле кушма җөмләдә — өтер яки ике нокта; туры сөйләм янында — сызык, өтер яки сызык, күп нокта һәм сызык, ике нокта һәм сызык; тиңдәш түгел аергычлар арасына өтер кую; берничә тыныш билгесе бергә очрашкан урыннарда ялгышу; үзара бик тыгыз бәйләнештәге гади җөмлаләрне өтер, сызык яки ике нокта белән аерып язу; тезмә кушма җөмләләрнең өлешләрен нокта белән аерып, шул фикерне гади җөмләләр итеп бирү) керә.

Контроль диктантларны бәяләү.

Бәяләү нормалары контроль диктант күләменнән чыгып бирелә. Язма эшләрнең күләме кимрәк яки артыграк булганда, нормалар да шуңа мөнәсәбәттә кими яки арта. Сыйныфлар буенча контроль диктант күләме түбәндәгечә билгеләнә:

| Группалар | Сүзләр саны | |
|---|---|---|
| | уку елы башында | уку елы ахырында |
| I курслар | 150 | 160 |
| II курслар | 160 | 170 |

**Текстны яздыру һәм язу методикасы**

Диктантны бәяләгәндә, орфографик һәм пунктуацион хаталар саны исәпкә алына.

Диктант язганда, укучы тарафыннан текстка өстәлмә һәм үзгәрешләр кертелми.

Укытучы диктант текстын укыганда, укучы нишләргә тиеш?

Игътибар белән тыңларга. Укытучы текстны бер кат сәнгатьле итеп укып чыккач, авыр аңлаешлы сүзләр яки фразеологик әйтелмәләр булса, аларны аңлата.

Диктант текстын укытучы җөмләләп яздыра, озынрак җөмләләрне, бер кат тулысынча укыгач, синтагмаларга бүлеп әйтә. Укучы, укытучы җөмләне синтагмаларга бүлеп әйткәндә, тыныш билгеләрен «куеп калырга» ашыкмасын. Чөнки синтагмаларга — мәгънәви

кисәкләргә бүлеп әйтү тыныш билгеләре булмаган урынга да туры килергә мөмкин. Шуңа күрә тыныш билгеләрен җөмләне тулысынча укыганда кую җайлырак булыр.

Укытучы тексттагы сүзләрне әдәби телнең орфоэпик нормаларына туры китереп әйтә, ләкин аларның дөрес язылышын искәртми. Бу очракта укучы барлык сүзләрнең дә әйтелеше язылышка туры килмәгәнлеген, сүзләргә (шул исәптән алынма сүзләргә дә) кушымча ялгану үзенчәлекләрен исегезгә төшерергә тиеш.

Укытучы аерым язылырга тиешле ярдәмлек сүзләрне төп сүздән пауза белән аерып әйтми, төп сүз белән бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең, төп сүз белән кисәкчәләрнең, төп сүз белән теркәгечләрнең язылыш үзенчәлеген искәртми.

Укучы җөмләне язып бетергәч, укытучы, дөрес интонация белән, аны тагын бер кат укый. Укучы бу очракта кушма җөмлә эчендәге гади җөмләләр арасына куелырга тиешле тыныш билгеләрен куя; гади һәм кушма җөмлә эчендә аерымланган иярчен кисәкләр дә булырга мөмкин — аларны тыныш билгесе белән ничек аерырга икәнен исенә төшерә; теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр эчендә куелырга тиешле тыныш билгеләрен барлый; синтетик һәм аналитик төрдәге иярчен җөмләләр белән баш җөмлә арасына куелырга тиешле тыныш билгеләрен куя; укытучының җөмлә ахырында ясаган интонациясенә карап, җөмлә ахырына куелырга тиешле тыныш билгесен куя. Диктант тулысынча язылып беткәч, укытучы текстны соңгы тапкыр сәнгатьле итеп укып чыга. Бу вакытта, укучы, беренче чиратта, җөмлә эчендә һәм ахырында куелырга тиешле тыныш билгеләренең куелышын тагын бер кат тикшерә. Аннары укучыга, язмасын мөстәкыйль тикшерер өчен, 3 — 5 минут вакыт бирелә. Бу вакытны тиешенчә файдаланып, укучы тагын бер кат һәр төп сүзнең һәм ярдәмлекләрнең язылышын карап чыга. Тикшерү ахырына ул һәр сүзнең язылышы, җөмлә эчендәге һәм ахырындагы һәр тыныш билгесенең куелышы дөрес дигән нәтиҗәгә килергә тиеш. Дөрес, бу — аның беренче нәтиҗәсе. Соңгы нәтиҗәне, эшне тикшергәннән соң, укытучы ясый. Ул укучының язмасындагы орфографик һәм пунктуацион таләпләрнең дөрес үтәлешенә бәя — билге куя.

**Истә тотарга кирәк:**

— бер үк хатаның бер үк сүзләрдә кабатлануы бер ялгыш итеп санала;

— бер үк хата төрле сүзләрдә җибәрелгән булса, һәрберсе аерым ялгышка исәпләнә;

— җөмлә ахырында тиешле тыныш билгесен куймау сәбәпле, икенче җөмләне юл хәрефе белән башлау очрагы бер пунктуацион хатага исәпләнә;

— текст эчендә туры сөйләмне программа таләп иткән дәрәҗәдә бирә алмау пунктуацион хата исәбенә кертелә; туры сөйләмне дөрес биреп тә, тыныш билгеләрендә хаталар җибәрелсә, аларның чит кеше сүзләрен бирүгә караганнары барысы бергә бер хата итеп санала;

— 5 нче сыйныфтан башлап, төзәтелгән хаталарның нинди төр хатага исәпләнүен күрсәтә торган шартлы билгеләрне поляда түгәрәк эчендә бирү бик уңайлы. Икесе бер тупас ялгыш итеп санала торган очракта берсе түгәрәк эченә алынмый;

— бер төрдәге яки бер үк кагыйдәгә караган хаталар ялгышлар санында тулысынча күрсәтелә. Бу очракта аларның саны теге яки бу уңай билге кую нормасыннан артып китәргә мөмкин. Шуңа күрә контроль диктантларда, жәяләр эченә алып, шундый ничә хата барлыгын күрсәтергә тәкъдим ителә. Мәсәлән, контроль диктантта хаталар саны 3 (2) (3 хатаның 2 се 1 төрдәге хата) рәвешендә күрсәтелә икән, ул эшкә «4» ле билгесе куеп була;

— укучының эшен бәяләгәндә хаталарның төрләре (орфографик, пунктуацион һ. б.) аерым-аерым исәпләнә һәм, шуларның барысыннан чыгып, бер билге куела;

**Югарыда саналганнардан чыгып, контроль диктантлар түбәндәгечә бәяләнә:**

| № | Таләпләр | Билге |
|---|---|---|
| 1. | Орфографик һәм пунктуацион хаталар булмаган эшкә.<br>**Искәрмә.** Орфографик (яки пунктуацион) хаталы пөхтә башкарылган эшкә яки бер үк хата бер үк сүзләрдә кабатланса һәм пунктуацион бер хаталы эшкә | «5»ле билгесе куела. «5» ле билгесе куела ала. |
| 2. | 1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган эшкә<br>**Искәрмә.** 1 орфографик, 2 пунктуацион хаталы эшкә яки орфографик хаталары булмыйча, 3 пунктуацион хатасы булган эшкә, яки бер төрдәге 2 орфографик һәм 1 пунктуацион хаталы эшкә | «4» ле билгесе куела. «4» ле билгесе куела. |
| 3. | 2 орфографик, 1—3 пунктуацион хаталы, 2 төзәтүле эшкә<br>**Искәрмә.** 4 пунктуацион. 1 орфографик хаталы эшкә яки бер төрдәге 5 орфографик, 4 пунктуацион хаталы эшкә | «3» ле билгесе куела. «3»ле билгесе куела. |
| 4. | 5 орфографик, 5 пунктуацион хаталы, 4 төзәтүле эшкә | «2»ле билгесе куела. |

### Грамматик биремле диктантларны бәяләү

Грамматик биремле диктантлар күләме ягыннан, I контроль диктантлар белән чагыштырганда, 10—15 сүзгә кимрәк була. Аларны тикшерү һәм бәяләү контроль диктантлардагы кебек үк эшләнсә дә, мондый диктантларга ике билге куела: беренчесе — диктантка, икенчесе — грамматик биремне башкару сыйфатына. Әгәр грамматик бирем бер дә ялгышсыз башкарылса, «5” ле куела, дүрттән өч өлеше дөрес башкарылмаган грамматик биремгә уңай билге куелмый.

### Сүзлек диктантларын бәяләү

Хатасыз башкарылган эшкә «5»ле, бер-ике хаталы эшкә «4»ле, өч яки дүрт хаталы эшкә «3» ле билгесе куела.

### Өйрәтү характерындагы язма эшләрне бәяләү

Өйрәтү характерындагы язма эшләр (төрле күнегүләр, контроль характерда булмаган диктантлар һ. б.), контроль эшләр белән чагыштырганда, таләпчәнрәк бәяләнә. Андый эшләрдә: а) укучының аны ни дәрәҗәдә мөстәкыйль башкаруы; б) укытучының кайсы вакытында (яңа белемнәрне үзләштерүгә әзерлек вакытында, үзләштерү процессында, ныгыту яисә кабатлау барышында, фронталь тикшерү чорында һ. б.) эшләнүе; в) эшнең күләме; г) ни дәрәҗәдә пөхтә һәм үз вакытында башкарылуы исәпкә алына.

Җибәрелүе ихтимал булган хаталар алдан искәртелгән очракта «5» ле билгесе ялгышсыз, «4» ле билгесе бер төзәтүле (укучы үзе төзәткән) эшкә генә куела. Ике хатасы булган эшкә «3» ле, өч-дүрт хаталы эшкә «2» ле билгесе куела.

Җибәрелүе ихтимал булган ялгышлар алдан искәртелмәсә, мөстәкыйль рәвештә башкарылган эшләр контроль диктант нормасы белән бәяләнә.

### Изложениеләрне бәяләү

Изложение язу өчен, гадәттә, укучыга аңлаешлы телдә язылган хикәяләү характерындагы текст яки өзек алына. Ул матур яки фәнни-популяр әдәбияттан, көндәлек матбугаттан һ. б. алынырга мөмкин.

Нинди генә өзек яисә текст бирелсә дә, укучы аның язылу стиленә игътибар итәргә, стильләрне бутамаска тиеш. Текстның стиль үзенчәлекләре укучының язмасында да сакланырга тиеш.

Изложениенең күләме һәм эчтәлеге, сыйныфның әзерлегенә карап, укытучы тарафыннан сайлап алына.

Изложение өчен матур әдәбият һәм фольклор әсәрләреннән, вакытлы матбугаттан хикәяләү характерындагы өзекләр яки текст алына. Тезмә әсәрләр нигезендә изложение сирәк яздырыла.

Сайланган текстлар укучыларга белем һәм тәрбия бирү максатларын канәгатьләндерерлек, эчтәлеге һәм теле ягыннан аңлаешлы булырга, бәйләнешле сөйләм үстерү юнәлешендә алып барылырга тиеш.

Текст белән эшләү барышында укучыларның бәйләнешле фикер йөртә белү сәләте генә түгел, ана теленең орфографик, грамматик, стилистик һәм пунктуацион үзенчәлекләрен белүләренә, текст эчтәлегеннән чыгып, нәтиҗә ясый белү сәләтенә, сүз байлыгыннан файдалана белү мөмкинлекләренә дә бәя бирелә.

**Изложение текстының һәм язма эшләрнең күләме (сүзләр белән) түбәндәгечә билгеләнә:**

| Курслар | Изложениеләр саны | Уку елы башында | | Уку елы азагында | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | текстның күләме | язманың күләме | текстның күләме | язманың күләме |
| I курслар | 2(1) | 475-500 | 240-250 | 500-525 | 250-260 |
| II курслар | 2(1) | 500-525 | 250-260 | 525-550 | 260-275 |

Изложение ярдәмендә укучыларнын түбәндәге белем, осталык һәм язу күнекмәләре тикшерелә:

1. Укучының эчтәлекне эзлекле, тулы һәм дөрес бирүе, бәйләнешле итеп яза алуы. Ягъни изложение тексты мөмкин кадәр төгәл бирелергә тиеш. Текстка үзгәреш бары тик иҗади (сочинение элементлары кертелгән биремле) изложениеләрдә генә кертелә.

2. Укучының тел байлыгы, сөйләмнең төгәл һәм образлы булуы. Сөйләм байлыгы дигәндә предмет, күренеш, вакыйгаларны тасвирлауда тиешле сүзләрне мөмкин кадәр урынлы куллану, күп төрле морфологик категорияләрдән һәм синтаксик төзелмәләрдән файдалану күздә тотыла. Сүз төрлелегенең чикләнгән булуы, сүзнең бер үк формаларын еш кабатлау, бер төрдәге гади җыйнак җөмләләр яки бертөсле синтаксик төзелмәләр белән генә эш итү укучы теленең ярлы булуын күрсәтә.

Сөйләм төгәллеге дигәндә сүзләрне контекстта дөрес мәгънәсендә куллану, контекст таләп иткән иң уңышлы синонимны файдалана белү, гади җөмләләрдә сүзләрнен, кушма җөмләләрдә гади җөмләләрнең бәйләнешен дөрес оештыра алу күздә тотыла.

Язуның образчылыгы исә үз эченә сүз һәм фразеологик әйтелмәләрне, сурәтләү чараларын (эпитет, чагыштыру, сынландыру, гипербола кебекләр) куллануны, һәр ситуациянең үзенә генә хас сөйләм төрен һәм стилен саклап язуны ала.

2. Грамоталы итеп яза алу дәрәҗәсе; укучының грамматик нормаларны һәм дөрес язу кагыйдәләрен саклап язу күнекмәләренә ия булуы.

**Изложениене яздыру һәм язу методикасы**

Теле һәм эчтәлеге ягыннан укучыга аңлаешлы текстны укытучы ике кат сәнгатьле итеп (сүзләрдәге авазларны ачык әйтеп, синтагма һәм җөмлә чикләрен тиешле интонация беяән дөрес билгеләп, җөмләләрдәге тиңдәш һәм аерымланган иярчен кисәкләрнең чикләрен билгели алырлык итеп, кереш һәм эндәш сүзләрне, туры сөйләм формаларын сиземләрлек итеп, фактик мәгълүматларга логик басым ясап) укып чыга.

Текстта укучыга таныш булмаган сүзләр, фразешогик әйтелмәләр тактага язып яки телдән аңлатыла.

Укытучы текстны укыганда, укучы нәрсәләр эшли ала?

Хәтерендә калдырырга авыр, ләкин эчтәлекне бирү өчен мөһим булган кайбер нәрсәләрне, мәсәлән, ялгызлык исемнәрен, даталарны, саннарны, аерым сүзтезмәләрне, туры сөйләмне һ.б. дәфтәр битенә теркәп барырга мөмкин.

Тексттагы фикер эзлеклелеге югалмасын өчен, үзе кирәк дип санаган фикерләрне язып бара ала. Ләкин укучы шуны истә тотарга тиеш: язып, теркәп барулары укыла торган текстны тулысы белән хәтерендә калдырырга комачауламасын.

Укучы язмасында текстның эчтәлеген генә «сөйләп чыгарга» тиеш түгел, ә бәлки, текстның (фәнни, публицистик, әдәби) стиль үзенчәлекләрен саклаган халдә, эчтәлекне мөмкин кадәр текстка якын бирергә тиеш. Ягъни укучы текстның эчтәлеген, эзлеклелеген үзгәртмичә, күләмен өлешчә (70% ка кадәр киметеп) үзгәртеп, сүз һәм җөмләләрне өлешчә файдаланып, аны әдәби язма телдә бирергә бурычлы. Шуңа күрә, укытучы текстны бер кат укыгач, эчтәлеге хәтерендә яхшырак калсын өчен, текстны, эзлекле итеп, эчтән генә сөйләп чыксын. Шуннан соң укучы изложениенең гади яки катлаулы планын төзи. Аннары, планга нигезләнеп, эчтәлекне тагын бер кат эчтән генә «сөйләп» чыга. Укытучы текстны икенче — соңгы кат укыганда, укучы эчтәлекне тулыландырырга, камилләштерергә, кирәк булган сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне «алып калырга» тырыша. Моның өчен абзац яисә җөмләләрдәге төп фикерне ачарга ярдәм итүче сүзтезмәләрне һәм сүзләрне төгәл бирергә омтылырга кирәк. Болай эшләгәндә, ягъни текстның «өлгесе» алынганда, эчтәлекне язмада тулы һәм аңлаешлы, эзлекле һәм бәйләнешле итеп бирү тагын да җиңеләя.

Текст соңгы кабат укылгач, укучы төзелгән планын тагын бер кат карап чыгып, кирәк дип тапса, өстәлмәләр кертә. Аннары, шул планга нигезләнеп, язмасының эчтәлеген һәм төзелешен тулысынча аныклап, ашыкмыйча гына яза башлый.

# ЯЗМАНЫ КАМИЛЛӘШТЕРҮ

Изложение язганда, укучы, текстның эчтәлеген язмасында эзлекле һәм дөрес бирү белән бергә, тиешле урында тыныш билгеләрен куярга, сүзләрнең ясалыш, язылыш, төрләнеш һәм бер-берсе белән ялгану үзенчәлекләрен, җөмлә төзелеше турындагы кагыйдәләрне истән чыгармаска тиеш. Ягъни язмада сүзне, бер сүзнең төрле формаларын кирәкле урында тиешле мәгънәсендә куллана, контекст таләп иткән синонимны, сурәт чарасын файдалана белергә гади җөмлә эчендәге сүзләрнең, кушма җөмлә составындагы гади җөмләләрнең бәйләнешен дөрес оештырырга, җөмләләр эчендә һәм ахырында тыныш билгеләрен дөрес куя белергә кирәк. Боларның барысы да текстның үзенә генә хас стилен саклап язарга ярдәм итә.

Тиешле урынында кулланылган һәр сүз, сүзтезмә, җөмлә, тыныш билгесе текстның эчталеген һәм стилен язмада төгәл бирүдә зур роль уйный. Шуңа күрә, һәр сүзне урынлы

куллану кирәк булган кебек, һәр тыныш билгесен тиешле урынына куярга кирәк. Аларны куймый калдырырга да, берсе урынына икенчесен куярга да ярамый. Шуны да истән чыгармагыз: текстта куелган һәр тыныш билгесенең язмада кабатлануы мәҗбүри түгел. Ягъни укучы текстта бирелгән кайбер кушма җөмлаләрне гади җөмләләр белән бирә; тиңдәш кисәкләр һәм кушма җөмлә составындагы гади җөмләләр арасындагы өтер, нокталы өтер урынына теркәгечләр, кисәкчәләр куллана яки, киресенчә, теркәгеч һәм кисәкчәләрне төшереп калдырып, алар урынына өтер, нокталы өтер кебек тыныш билгеләрен файдалана ала.

Сыйныфның әзерлеген искә алып, укытучы, алда үтелгән теманың үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү максатыннан, грамматик бирем дә бирә ала.

**Изложение түбәндәгечә бәяләнә:**

| № | Текстның бирелеше | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1. | Текст, планга нигезләнеп (яки плансыз), эзлекле бирелгән; стиль бердәмлеге сакланган; фактик һәм техник хаталар юк. | 1 орфографик яки пунктуацион (яки грамматик) хата бар. | «5» ле билгесе |
| 2. | Тексттагы хикәяләү агышы бирелгән эзлеклелек белән тулысынча туры килми; стиль бердәмлегендә хилафлык сизелә; язмада 1 фактик, 1 техник хата җибәрелгән. | 2 орфографик, 1 пунктуацион (яки 1 грамматик) хата бар. | «4» ле билгесе куела. |
| 3. | Текст язмада эзлекле бирелмәгән, стиль бердәмлеге сакланмаган. Сүзләр бәйләнешендәге төгәлсезлекләр җөмләнең мәгънәсен бозуга китергән. Язмада 1 фактик, 2 техник хата җибәрелгән. | 3 орфографик, 2 пунктуацион,1 грамматик хата бар. | «3» ле билгесе куела. |
| 4. | Тексттагы эзлеклелек язмада сакланмаган; стиль бердәмлеге юк; сүзләр һәм җөмләләр бәйләнешендә хаталар бар; фактик һәм техник хаталар күп. | орфографик хата-ларның саны өчтән, пунктуацион хаталарның саны икедән, грамматик хаталарның саны өчтән артык | «2» ле билгесе куела. |

**Сочинение түбәндәгечә бәяләнә:**

| № | Эшнен эчтәлеге һәм теле | Грамоталылыгы | Билге |
|---|---|---|---|
| 1. | Эчтәлек темага туры килә; язмада фактик ялгышлар юк; план буенча (яки плансыз) эзлекле язылган; теле бай, образлы; стиль бердәмлеге сакланган. | 1 орфографик (пунктуацион яисә грамматик) ялгыш бар | «5» ле билгесе куела. |
| 2. | Язманың эчтәлеге темага нигездә туры килә, ул дөрес ачылган; 1 фактик хата җибәрелгән, хикәяләү эзлеклелегендә артык әһәмияте булмаган бозу сизелә; тулаем алганда, теле бай, образлы; стиль, бердәмлеге | 2 орфографик, 2 пунктуацион һәм 2 грамматик ялгыш бар. | «4» ле билгесе куела. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | сакланган.<br>Эчтәлекне бирүдә мөһим читләшүләр бар: ул нигездә дөрес, ләкин фактик төгәлсезлекләр очрый, хикәяләү эзлекле түгел; теленең ярлылыгы сизелеп тора; синонимик сүзләрне аз куллана, бертөрлерәк синтаксик төзелмәләр файдалана, образлы түгел, сүз куллануда ялгышлар җибәрә; стиль бердәмлеге сакланып җитмәгән. | 3 орфографик, 3 пунктуацион һәм 3 грамматик ялгыш бар. | «3»ле билгесе куела. |
| 4. | Тема ачылмаган; фактик төгәлсезлекләр күп; планга туры килми, эзлеклелек бозылган; теле ярлы; сүз куллану ялгышлары еш очрый; стиль бердәмлеге юк. | 7 орфографик, 7 пунктуацион һәм грамматик ялгышлар бар. | «2» ле билгесе куела. |

Язма эштән соң беренче юлга, кызыл юл турысыннан башлап, ялгышларның саны күрсәтелә: башта орфографик, аннан соң пунктуацион һәм стилистик хаталар саны языла. Аларны ике нокта аша күрсәтергә була: 1:3:2. Бу язылыш 1 орфографик, 3 пунктуацион, 2 стиль хатасы барлыкны аңлата.